ГЛАВА ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская д.54 а, с.Верхняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 54 а нче йорт, Югары Ушма авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
“29 ” октябрь 2020 ел.

Постановление
№ 3

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хэсэнша авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Хэсэнша авылы , Ленин урамы , 37 нче йорт адресы буенча урнашкан Хэсэнша авылы клуб бинасында 2020 елның 16 нчы ноябрендэ сәгать 13.00 . Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хэсэнша авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хэсэнша торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау: (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Хәсәнша торак пунктында, Ленин урамы;

- Хэсэншэ торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;

- Хэсэнша торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитетына Хэсэнша авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы: И.З.Исмэгыйлев